| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**КАРАР** **КАРАР**

2015 елның 30 октябре Буа шәһәре 7-46 нчы номерлы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Буа муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

Карар:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Буа муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга, кушымта нигезендә.
2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021 – 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет-финанс мәсьәләләре буенча Буа район Советының даими комиссиясенә йөкләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Буа муниципаль районының рәсми сайтында.

Буа муниципаль районы
башлыгының беренче урынбасары,
Совет рәисе урынбасары И.Ф. Еремеев

Буа муниципаль районы Советы
2019 елның 30 октябре
7-46 нчы номерлы карарына
Кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Буа муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Буа муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр Буа муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча (алга таба – субсидияләр) Буа муниципаль районы Башкарма комитетының норматив-хокукый актларында билгеләнгән түбәндәге очракларда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә.

2. Субсидияләр Буа муниципаль районы Советының «Буа муниципаль районының 2020 елга һәм 2021-2022 елларның планлы чорына бюджеты турында» гы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. «Буа муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы»МКУ әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен төп бүлүче булып тора.

4. Буа муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләрне бүлү Буа муниципаль районы Советының «Буа муниципаль районының 2020 елга һәм 2021-2022 елларның планлы чорына бюджеты турында»гы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирүнең максатлары һәм тәртибе Буа муниципаль районы башкарма комитеты һәм Буа муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында төзелә торган килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм аны тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны тормышка ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү Буа муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты Буа муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан Буа муниципаль районы башкарма комитетларына җибәрелә.

9. Килешү Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе һәм Буа муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре тарафыннан имзалана.

10. Буа муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары субсидия алу өчен, Буа муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән срокларда түбәндәге документларны Буа муниципаль районы башкарма комитетына тапшыра:

Буа муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирүгә гариза һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга ихтыяҗны раслаучы башка документлар.

11. I-җирлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә::

$$С_{МТ} = П_i * У_i * К_i$$

монда:

$С_{МТ}$ – Буа муниципаль районы Советының «тиешле финанс елына һәм план чорына Буа муниципаль районы бюджеты турында» гы карары нигезендә билгеләнгән субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме, Буа муниципаль районы бюджетының керем мөмкинлекләреннән һәм Буа муниципаль районы шәһәр, авыл җирлекләренең чыгым ихтыяҗларыннан чыгып;

$П_i$ – i-җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Буа муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында финанс ярдәме күрсәтү ихтыяҗы күләме;

$У_i$ – i-җирлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслашуның иң чик дәрәҗәсе Буа муниципаль районы бюджетыннан;

$К_i$ – ул Буа муниципаль районының консолидацияләнгән бюджетының суммар ихтыяҗлары һәм керем мөмкинлекләре бәяләрендәге аерма нисбәтенең әһәмиятенә бәйле рәвештә билгеләнә.

12. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан җирлекләр бюджетларына федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен килешүдә билгеләнгән срокларда ачылган территориаль органнары счетларына субсидияләр күчерелә.

13. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Буа муниципаль районы бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

14. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидия калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Буа муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тоту эчке финанс контролен гамәлгә ашыручы орган тарафыннан закон нигезендә башкарыла.